РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай ав. **КАРАР**

« 12» ноябрь 2024 ел № 10

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 29 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Якты Күл авылы, Үзәк урам, 30Б адресы буенча урнашкан Якты Күл КФҮ бинасында Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл авылында Үзәк, Клуб, урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2024 елның 29 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Елга урамы буенча 24нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл авылында Елга урамында, Елга тыкрыгы урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә

3. 2024 елның 29 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Елга урамы буенча 24нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл авылында Юл буе урамында, Болын урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Якты Күл авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл авылы территориясендә теркәлгән 1 гр инвалидлардан кала., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан кала һәр

балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп ризамы:

- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу)».

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл торак пункты мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Ханәфиев

: